Рузил Фазлыев

# Хыял + Чынбарлык

Шигырь. Том 7. Стихи

Рузил Фазлыев

# Хыял + Чынбарлык. Шигырь. Том 7. Стихи

«Издательские решения»

**Фазлыев Р.**

Хыял + Чынбарлык. Шигырь. Том 7. Стихи / Р. Фазлыев — «Издательские решения»,

ISBN 978-5-00-591523-8

Бу китап алдагы китапларның дәвамы. Шигырләрнең күпчелеге вөгазь стилендә язылган. Электрон китап үзләштерүгә ясалган беренче адымнар.Иң беренче электрон китап булып кала.КИТАПЛАР, КИТАПЛАР…ЯЗМЫШТА ХИСАПЛАР.УЗГАННАР, ЯЗГАННАР…КЫЛЫНМЫЙ КАЛГАННАР… Үткән гомер аккан сулар кебек, агаларда көннәр агалар…Китапларга сыеп бетә алмас, ул вакытта үткән аралар…Уй фикерләр ага алмый инде, бары тамалар…Әйтелмичә, ишетелмичәдә калалар…

ISBN 978-5-00-591523-8

© Фазлыев Р.
© Издательские решения

# Содержание


| | |
|---|---|
| Хыял+чынбарлык | 8 |
| Ерак юллар | 9 |
| Тарих булып | 10 |
| Җәйнең төне | 11 |
| Әрем исе | 12 |
| Ерак офык | 13 |
| Байракчы | 14 |
| Адашып | 15 |
| Сүзләр | 16 |
| Чара юк | 17 |
| Уйлыйбызмы | 18 |
| Күңел дәфтәре | 19 |
| Соң булсада | 20 |
| Җәйләр китә | 21 |
| Көзме | 22 |
| Кайту җире | 23 |
| Ышанмаучылар | 24 |
| Күңел ачкычы | 26 |
| Җәйле еллар | 27 |
| Тынычмы | 28 |
| Якташ | 29 |
| Үткән җәйләр | 30 |
| Бүгенең | 31 |
| Дөнья гәепле буламы | 32 |
| Кабатланмас | 33 |
| Стаканида | 34 |
| Яңадан | 35 |
| Печән чапкан вакыт | 36 |
| Гомер җиле | 37 |
| Җәйнең киче | 38 |
| Күңелгә мунча | 39 |
| Барабыз | 40 |
| Җыр күңелдә | 41 |
| Тибә йөрәк | 43 |
| Бөдрә таллар | 44 |
| Тамырлар | 45 |
| Кимчелек | 46 |
| Кояш баеп килә… | 47 |
| Вакыт бар ул | 48 |
| Сөенү | 49 |
| Хыял аты… | 50 |
| Тәүбә кая… | 51 |
| Кая була вакыт | 52 |
| Утырасы иде | 53 |
| Күңел нинди | 54 |
| Авыл бетми | 55 |

Соңгы өмет 56
Биектә 57
Бер сандыкта 58
Гаделлек 59
Туган нигез 60
Җәй рәхәте 61
Таңнары, чишмәләре 62
Ялгыш «тумыш» 63
Чынбарлык 64
Юлда барасы 65
Гомер юлым 66
Челләсе 67
Конец ознакомительного фрагмента. 68

# Хыял + Чынбарлык
# Шигырь. Том 7. Стихи

# Рузил Фазлыев

© Рузил Фазлыев, 2022

ISBN 978-5-0059-1523-8 (т. 7)
ISBN 978-5-0056-9347-1
Создано в интеллектуальной издательской системе Ridero


Хыял+
чынбарлык
Бик беләсе килә иртәгәсен,
Ниләр безне көтеп торганын.
Көтмисендә кебек алай артык,
Хыялларда гына булганын.
Кайда ничек аның урыннары,
Өметләрең, хыял, чынбарлык?
Авыр сынаулары кайда көтә,
Көчең җитә алып, чыдарлык?
Искитәрлек, кеше язмышлары,
Барысыда аңа бирелгән....
Үзе сайлап барган юлларында,
Таба алу... туры киленгән...
Яхшы әкият кебек бөтен тормыш,
Кызыл сызыкларын тоя алсаң.
Аның чынбарлыгын, хыял белән,
Тоташтырып әгәр куя алсаң.
Үпкәләргә, күңел төшерергә,
Сәбәпләр юк җирдә торганда.
Язмышыңны алдамаска теләп,
Үзеңәдә , ихлас булганда...
Рузил Фазлыев
21.08.2021

# Хыял+чынбарлык

Бик беләсе килә иртәгәсен,
Ниләр безне көтеп торганын.
Көтмисеңдә кебек алай артык,
Хыялларда гына булганын.

Кайда ничек аның урыннары,
Өметләрең, хыял, чынбарлык…
Авыр сынаулары кайда көтә,
Көчең җитә алып, чыдарлык.

Искитәрлек, кеше язмышлары,
Барысыда аңа бирелгән…
Үзе сайлап барган юлларында,
Таба алу… туры киленгән…

Яхшы әкият кебек бөтен тормыш,
Кызыл сызыкларын тоя алсаң.
Аның чынбарлыгын, хыял белән,
Тоташтырып әгәр куя алсаң.

Үпкәләргә, күңел төшерергә,
Сәбәпләр юк җирдә торганда.
Язмышыңны алдамаска теләп,
Үзеңәдә, ихлас булганда…

# Ерак юллар

Еракларга юллар алып китте,
Туып үсеп җиткән җирләрдән.
Ничә тапкыр хисләр яңаралды,
Шул юллардан кайтып килгәннән.

Каршы ала, озатып кала иде,
Басу капкалары булганда…
Чик сакчысы кебек, үткәннәрне,
Тыныч кына, карап торганда…

Яңгырлары күпме юлдаш булды,
Ул капкалар аша үткәндә…
Күпме кеше белә алмый калган,
Кайта алмаска чыгып киткәндә.

Язмышларны бүлеп урталайга,
Ул капканың ике ягына…
Кушыла алмый, нидер югалгандай,
Җитә алмый кеше җанына.

Сирәк кеше кире бара ала…
Киткән юллар алар, түгелдер.
Үткән юлын сагынып уйланучы,
Моң чолгаган ялгыз күңелдер…

# Тарих булып

Тарих булып кала балачаклар,
Һәр язмышның үзе тарихы.
Күпме алар сакланырлар икән;
Гомерләрнең үтеп барышы…

Ялан аяк йөрү, иң беренче,
Карлар эреп чирәм чыгуга.
Ачу килеп, үпкәләшеп китү,
Ялгыш кына этеп егуга…

Чиксез кебек колхоз басулары,
Чөгендерен кемнәр оныткан.
Олы кеше кебек караңгыда,
Тәүге тапкыр кайту клубтан…

Каникуллар, колхоз эшләрендә,
Яшьләренә карап эше бар.
Ул вакытны татып карамаган,
Балачакта, нинди кеше бар.

Күпләр белми тирес сугуларны,
«Утын» итеп кышын ягарга.
Буш вакытлар каян булды икән,
Урамнарда, тагы «чабарга»?

Булды микән ат җикмәгән кеше,
Кышын, көзен, җәен, язларын.
Хәтирәләр булып калсаларда,
Үтә алганбыз бит, язганын.

# Җәйнең төне

Җәйнең төне урамнарда,
Эселектә… бик тиз сүрелгән.
Караңгылык юрганына,
Бу мизгельдә ул төренгән.

Бөтен, җиһан йоклагандай,
Берән сәрән, төнге тормыш…
Мондый төндә кайберәүләр,
Кыргын эшен әле кылмыш.

Төннәр кыска булсаларда,
Алыштыра яңа көнне.
Төннәрдән соң көтәбез бит,
Таңнарын һәм яңа көнне.

Төннәр алар яллар өчен,
Бөтен җиһан яллар итә.
Көннәр төннәр алышынып,
Җирдә гомер дәвам итә.

# Әрем исе

Әрем исен кемнәр хәтерләми,
Авылларда туып үскәннәр…
Әрем исе кебек ачы диләр,
Кайвакытта инде үткәннәр.

Ачы әрем исе, ачымы соң…
Әрем исе ачы булалмый.
Башкалары… кеше күңеленә,
Әрем исе кебек тулалмый.

Әрем исе, җәйнең исе кебек,
Хәтерләрдә кала уелып…
Тарата ул җилдә хуш исен,
Күзләр җитми, бетми коелып…

# Ерак офык

Нәфес микән диеп шикләнәмдә…
Нидер җитмәгәнгә, бүгендә…
Кояшта бар, ае, йолдызларда,
Бер карасаң җиһан күгендә.

Борчылумы, әллә курыкумы,
Киләчәкне уйлап кайвакыт.
Онытыла тормыш асыллары,
Бу дөньяда артык кайнашып.

Бердәмлеге бик күп кешеләрнең
Язмышларын якын кыла ала.
Битараф һәм таркаулыкта калып,
Мохтажлыкка сәбәп була ала.

Онытыла, элек халык әйткән:
Бүленгәнне… аеырылганны сүзе.
Уртак тормыш бергә төзелә бит,
Сизмәсәдә кеше аны үзе.

Бергә яшәү, колхозларга кереп,
Аеырым хуҗалык кына булмыйча.
Күрше, туган, дуслар, фикердәшләр,
Бер берсеннән читтә тормыйча.

Башкагада телә, үзеңә теләгәнне,
Җавап булып кайтар үзеңә.
Уртак тормыш, уртак фикер белән,
Тыныч тормыш бары төзелә.

# Байракчы

Үз байрагың бар чагында,
Чит әләмнәр күтәрмә.
Үз халыкың якын булса,
Хезмәт итмә бүтәнгә.

Император флаглары,
Кемнәр өчен якындыр…
Ике флаг күтәргәннәр,
Ике ирле хатындыр…

Илләр символы флаглар,
Билгедә ул, тамгада…
Ике байрак була алмый,
Кыйбласы баргада.

Кызыл флаг, аклы зәңгәр,
Кемнәр кемгә сатылды.
Кемнәр ихласырак булган,
Менә хәзер ачылды…

Яшь пионер комсомоллар,
Күптән үсеп җиттеләр…
Патша байрагын күтәреп,
Дөнья буйлап киттеләр.

Ялган булган барысыда:
Тантаналы… антлары.
Ленин бабай юлдашлары,
Капиталист картлары…

# Адашып

Без ниләр күрмибез…
Аңламый, белмибез.
Кыйбласыз яшибез,
Иманга килмибез…

Бары тик байлыгын,
Дөньяның сөябез…
Кешегә буйсынып,
Башларны иябез…

Зыяны юк бит, диеп,
Шайтанда дус була.
Шуңада… савапсыз…
Күңелләр буш була.

Иманнан еракта,
Гомерләр узганда…
Тыйганнан тәм табап,
Имансыз булганга…

# Сүзләр

Әй бу сүзләр, ниләр генә кылмый,
Күңелләрне ничек яралый…
Ачу белән бергә туган сүзне,
Уйламыйча әйтү ярамый…

Сүзләр генә дибез кай вакытта,
Ә алар бит, күңел карашы.
Шул карашың сиңа маяк булып,
Ул юллардан алга барасы.

Сүзләр алар, салган күперләрдә,
Җимерелгән йортлар гайләләр.
Алар әле тормыш законнары,
Дөрес юлдан безне әйдәгән.

Буш сүзләргә вакыт исраф булса,
Авырлары, җанны яралый…
Яралы җан, ялгыз җафалана,
Бер эттә аны, килеп яламый.

Кеше булып калу кыенырак…
Ходай биргән безгә телләр бар.
Яра салмый, яра алмый калган,
Белмим, бу дөньяда кемнәр бар.

# Чара юк

Кемгә авыр, кем күнегә,
Замана шартларына…
Сәбәпләре иксез чиксез,
Борчуга… шатланырга.

Кеше түзми, яраклаша,
Камбала балыгыдай…
Балык кебек сөйләшербез
Дөньялар барса болай.

Ашыгалар чәйнәүчеләр…
Сагызлардан туйдылар.
Кеше чәйнәп… тамак ялгап,
Акылларын җуйдылар.

Хәкимнәрдә гаеп микән,
Алар – язмыш коллары.
Гыйбрәт алып калу өчен,
Яшәүе… һәм булганы…

Шуңада әйткәннәр инде,
«Кабатланмый язмышлар».
Әллә безгә» сәләм бирә»,
Кайтып, кылган ялгышлар…

# Уйлыйбызмы

Зарланганга, зар өстәлә,
Шат булалсаң, шатлык килә.
Ихлас белән сораганда,
Бирми калмый, барыбер бирә.

Сыйфатларың бары юлдаш,
Начар сыйфат тормыш боза,
Ничек кенә яшәсәкдә,
Язмыш юлы үтә, уза…

Иманлыда… имансызда,
Көн артыннан көн уздыра.
Кем кадерен белә ала…
Әрәм итеп, кем уздыра.

Начар юллар ник сайлана,
Матур булып күренгәнгә…
Кушылганнар үтәлмичә,
Шикле әйбергә үрелгәнгә.

Нәфес көчен җиңәлмыйча,
Хыялларың сүрелгәнгә.
Чишмә суы кебек тормыш,
Әчә алмый түгелгәнгә.

Язмыш юлы язылсада,
Язылганны уку кирәк…
Кояш сүнгән кебек җирдә,
Сәгать чаңы сугар кинәт…

# Күңел дәфтәре

Ярый әле артка карап була,
Искә алып инде үткәнне.
Юл башыннан инде ерагырак,
Аңлый алып… шактый киткәнне.

Күңел дәфтәрендә барысыда,
Иренмичә бары карыйсы.
Китап шикелле үк булмасада,
Калын дәфтәр, болай ярыйсы.

Шулдыр инде булган байлыгың,
Кирәк чакта ачып карарга.
Онытканны искә төшерергә,
Югалтканны эзләп табарга.

Серләредә, шунда яшерелгән,
Хыял булып калган күпләре.
Бөтенесе анда сакланадыр,
Кеше гомерләре үткәне..,

Кулга алыр вакыт шул дәфтәрне,
Көндәлектәй карап «актарып»…
Уфтанырлык урыннарын табып,
Тыныч кына кайчак «мактанып».

Башка берни аңа өстәп булмый,
Дәфтәр тулган, язар урын юк…
Язылганнан башка бер адымда,
Синең инде үткән юлың юк.

# Соң булсада

Адашулар бары юлчы өчен,
Алдашулар читен сүзсезгә.
Барысыда шулай языладыр,
Авырлыкка кеше түзсенгә.

Хыял юлларында бәхет эзләп,
Күпме вакыт китә әрәмгә…
Гомер үтә, вакыт җитә алмый,
Карар өчен күккә, галәмгә…

Дөнья ача һәркем үзе өчен,
Аңламыйча булган канунны.
Кеше сайлый, хыялына багып,
Сукыр кебек юлдан баруны…

Үз юларын таба бик күпләре,
Үтәр юллар инде беткәндә…
Бик соңарып килгән бәхеттәй,
Ерак булган… аны көткәндә.

Тормыш мәшәкате күмеп китә,
Чүп үскәндәй барыр юлларга.
Шуңада ул соң булсада килә,
Язмышыңда синең булганга…

# Җәйләр китә

Йолкып алган кебек күңелемнән,
Бу жәйләрнең соңгы көннәрен.
Җәйнең яңалары якын кебек,
Булмагандай җәйләр күргәнем…

Җимешләре җәйнең акырынлап,
Агачлардан җиргә коела.
Язмышларда җәйләр кебек үтә,
Булмаганда кебек… тоела.

Эсселектә, салкын җиле исеп,
Ялган рәхәтлек булсада…
Шөкер итә алыр идек микән,
Еллар буе җәйләр торсада.

Шуңадырда сары яфраклар,
Яшел җәйнең төсен үзгәртә.
Беләбезме җәйнең кадерләрен,
Ничә тапкыр җәйләр күрсәктә.

Балачаклар ихлас чаклар була,
Ятып чирәмнәрдә аунарга…
Вакыт җитми әдәм баласына,
Яшәү рәхәтлеген аңларга…

# Көзме

Кемнәр белә язмыш көзе кайчан,
Картлык көне генә буламы…
Әллә инде күптән узып киткән…
…Сизелмичә бүген узамы…

Ниләр эшли алып язын – җәен,
Иң кыйммәтле матур чорларын.
Җыя алып күпме хисләреңне,
Хәтер йомгагына чорнадын…

Тоя алып кояш нурларыннан,
Яктылыклар, табып өметләр.
Исрафка үткән вакыт өчен,
Кемнәр микән килеп үгетләр.

Сүнмәс учак булып яшәү дәрте,
Кабына алып көчләр биргәндә.
Читтә калмый, сәләм бирделәрме,
Кайгы, шатлыкларың килгәндә.

Мактанулар яки макталулары,
Кеше өчен артык кыйммәтме.
Җирдәгесе, җирдә генә кала,
Төзәтәсе барысын килмәсме.

# Кайту җире

Тагын үттеп китә шулай җәйләр…
Быел менә тагын кайталмадым.
Җылы хисләр инде үткәннәрем,
Кайчан җае килеп, кайталганым.

Ике җирдә бергә булу кыен,
Ике юлның берсен сайлыйсың.
Кайвакытта сәбәп булмагандай…
Барыр җирләргәдә бармыйсың.

Кирәге бар… тиешләре бик күп,
Кайсын ташлап, кайсын башларга.
Күпмеләре үтәлмичә кала…
Теләкләрең баштан ашканда.

Кайту сүзениләр аңлата соң,
Булса синең торган җирләрең.
Ниләр бирә синең күңелеңә,
Туган якка кайтып килгәнең.

Берәү генә кебек кайту җире,
Кая тартса синең күңелең…
Аңлый алу, язмыш кайчан яза,
Кайтмый калу мөмкин түгелен.

# Ышанмаучылар

Матур исем уйлап табалганнар,
Имансызга медаль – атеист…
Асылында ниләр ята икән,
Әллә артист, әллә аферист…

Ышанмаучы кеше булганына,
Ялган булган әйткән сүзләре.
Хезмәтчеләр булды тыңлаганнар,
Сизмичәдә калып үзләре…

Коммунизм әнә үтеп китте,
Атеистлар калды коелып.
Бердәм байлар өйе ясадылар
Бөтен буржуй бергә жыелып…

Кара төтен чыга торбалардан,
Кара болыт булып күкләргә.
Нефть акчалары кая ага,
Билгеледә түгел күпләргә.

Халык шул ук, алар кая барсын,
Үз өлеше аңа эләкте…
Ул тырышып олы йорт төзеде,
Буржуй аннан налог түләтте…

Яшь ялагай күптән бабай булды,
Ышануы буенча атеист…
Асылында ничек булды микән,
Әллә артист, әллә аферист.

Татарчасы гади булган икән:
«Ышанмаучы, ерак иманнан.
Коммунизм диеп алдаганнар,
Үзләренө байлык җыйганнар.

Халыкныкы – аларныкы булды,
Нефть вышкаларын бүлделәр.
Яңа хуҗалардан дөнья тулы,
Кешеләрдә аңа күнделәр…

Ыспай атлап яңа хуҗа киլә..
Озатып йөри дуслар- куштаннар.
Машинада озак утырганнан,
Йомарланып беркән ыштаннар.

Кешеләргә табыну олы гөнах…
Озакламый булыр җимеше.
Байлык белән коллык җитәкләшеп,
Безгә кабат кайтып килеше…

# Күңел ачкычы

Күңел ачкычлары диелә бит,
Теләк теләп дога кылганда.
Тәүге адымынны тоя алып,
Гыйбәдәткә теләк туганда.

Күңел ачкычлары бирде дибез,
Хикмәтләрне бераз аңласак.
Күңелләргә юлын таба ала,
Иман сүзен тирән санласак…

Ябык күңел берни кабул итми,
Нинди генә вагазь булсада.
Кеше күңеленә салып булмый,
Изге сүздән генә торсада…

Хикмәт сүзе – ул күңелгә ачкыч,
Таба алу андый сүзләрне…
Ә бүләкли Раббымыз бары,
Иман юлларында түзгәнне.

Ачкыч бирсен безнең күңелләргә,
Иман нурларына ачарга…
Тәүбәгә дә, гыйбәдәтләргә дә,
Юллар ачык була кайчанда…

# Җәйле еллар

Кичә генә килгән кебек җәйләр,
Бүген инде күзгә ялгана…
Эсселәре булды… ә җылысы,
Җиталмаган кебек җанга да.

Җәйләрне бит тотып карагандай,
Матурлыгын тоя алуың…
Ничә тапкыр гомер юлларында,
Җәйле еллар җыя алуың…

Җәйге еллар диеп исемләдем,
Хәтерләрдә уелып калганын…
Матур чаклары дип гомерләрнең,
Еш сагынып искә алганын…

Күңелләрдә чәчәк аткан чаклар,
Олы юллар, көтә… чакыра…
Хисләр белән яши торган вакыт,
Ашыккан чак юллар чатына.

Җылы вакыт, язмыш юлларының,
Бөтен тормыш җәйләр шикелле.
Шуңа атадым җәйле еллар диеп…
Җәйләр кебек үтеп кителде…

# Тынычмы

Тыныч кына кемдер яшәп ята,
Тамагым тук, өстем бөтен дип.
Бүгенгесе бары учак булса,
Калганнары аның төтен дип.

Юлга чәчеп булган ядкәрләрне,
Дога тапмый, тотып укырлык.
Нигә диеп сорап торасыда юк,
Кеше арбасына утырдык…

Табынулар китте ялтырыйкка,
Шәмнәр тотып бәйрәм итәбез.
Кая баруларны белә алмый,
Озакламый «барып җитәбез»…

Битарафлык гади әйбер хәзер,
Кысылмыйча яшәү, файдалы…
Алыштырып телне, динне, илне,
Тормышларын күпләр «җайлады»,

Онытыла иман, әдәб сүзе…
Имансызлык кабул ителә.
Гаделлек һәм намус сүзе кая,
Аларсызда… тормыш ителә.

Болар барсы яңа әйбер түгел,
Бик күп еллар элек язылган…
Иман зәгыфлеге авыруы,
Безгә бүген килеп кагылган.

# Якташ

Якташлар була авылдаш,
Авылдан ерак барсаң…
Райондашта якташ була,
Шәһәрдә яшәп калсаң.

Казаннан да ерагайганда,
Татарстан – якташлар…
Чит илгә чыгып киткәндә,
Кемнәр була якташлар…

Ватандашлар якташлармы,
Бергә яшәп яткачтан…
Туган ягын оныталмый,
Туган яктан ятлашкан.

Сабакташлар, иптәшләр,
Хезмәттәшләр, акбашлар…
Кая гына барсакта без.
…Кеше өчен якташ бар.

# Үткән җәйләр

Күпме үтә шундый матур җәйләр,
Ак болыттай ага гомерләр…
Үтелмәсә озын язмыш юлы,
Була алмас иде, бүгеннәр…

Ә хыяллар… күпме алар туган,
Җәйләр килсә, инде бигерәк.
Еракларга күңел тарта иде,
Кошлар омтылгандай биегерәк.

Һаваларга карап хыялланып,
Чалкан ятып, яшел чирәмдә.
Хыялларың бик тирәндә чак та,
Әйтә алмый, әйтим дигәндә.

Авыр вакытлары… сынаулары,
Бетмәс кебек булган чаклары.
Сабырлыклар, аңламыйча әле,
Ул вакытта безне яклады…

Җирдә үсеп, җирдә без өйрәндек,
Адым, адым итеп үтә алып…
Алган гыйлем, булган акыл белән,
Олы юлга чыгып китә алып…

Җәйләр кабатланып торсаларда,
Юллар кебек алар үтәләр…
Сизелмиләр, әллә көтмәгәнгә,
Ялт иттереп… көзләр җитәлә.

# Бүгенең

Артка карап, алга барам бугай,
Буйсындырып булмый уйларны.
Якын итеп әллә кайчан үткән,
Күңел түрләренә куйганны.
Ерактагы сабантуйларны…

Сибелгәндәй үткән юлларымда,
Җыя барган бөтен күчтәнәч.
Онытканы… күңелләргә ул чак,
Хисләр булып кабат күчмәгәч.
Хәтердә гөл булып үсмәгәч.

Язылганнар күңел дэфтәренә,
Хәзер бары, аны укыйбыз…
Шактый әйбер анда язылганга,
Уйланырга, кайчак туктыйбыз.
Онытылып аннан йоклыйбыз…

Дөрләмидә… бары үтеп бара,
Сүнгән учак кире кабынмый…
Мохтаҗлыктан- булган ул җылыны,
Чаралар юк… бары сагынмый.
Башка юлы барыбер табылмый.

Бер мизгеле кинәп тотып калып,
Җибәрмичә озак йөргәндәй…
Тикшерергә теләп хисләреңне
Уйларыңны синең белгәндәй.
Синең бүгенеңнән көлгәндәй.

# Дөнья гәепле буламы

Дөнья гәепле буламы,
Кешеләрдә бармы эше.
Авырлыклар килгән чакта,
Дөньяга сылтый кеше…

Абынсада, егылсада,
Еласада утырып…
Шөкер әйтми гомер буе,
Язмышларын тутырып.

Үзебездән эзләүләр юк,
Ахмаклыкка гаепне…
«Акыллы баш» гөнах кылса,
Нишләп дөнья гаепле?

Дөнья ул бер, барыбызга,
Ул гаепле була алмый.
Яшәү өчен безгә куыш…
Язмышларны бозалмый.

Без кунаклары дөньяның…
Аннан гаеп эзлибез…
Кем булабыз без шуннан соң?
Ансын инде… «белмибез»…

# Кабатланмас

Кабатланмас инде ул вакытлар,
Ничек кенә искә алсаңда…
Артка борылып, син карасаңда,
Уйларыңа һаман салсаңда.

Юллар ерак… башка баралмаслык,
Булсалардә әле уйлар зирәк…
«Кабатланмас» сүзен аңларгада…
Булганына ризалалашу кирәк.

Балачакта, хәзер син ят кеше…
Яшьлегеңдә кемнәр таныр соң.
Кайту мөмкин булса үткәнеңә,
Анда да син, ялгыз калырсың.

Сагынуны моңнар гына баса,
Аннан башка аңа дару юк…
Гомер юлы бары алга бара,
Артка таба анда бару юк…

Кичерешләр алар эзләр генә,
Син калдыра алган, үткәндә.
Юанычлар алар түгел мени,
Борчылганда гомер үткәнгә.

Бөтенесе бергә нигъмәт кенә,
Күңелләргә булып хәрәкәт.
Кемнәр белә… тормыш көзләрендә,
Шулай бәлки… килә бәрәкат…

# Стаканида

Кемнәр соң без кайда яшибез,
Нинди илдә нинди халыклар.
Рәхәттән һаман туялмаган,
Гаделлектән әллә ялыккан…

Без күчкәнме әллә, яңа илгә,
Гөнахлылар өчен төзелгән.
Барсы биргә, бае, хәерчесе,
Ярлыкаудан өмет өзелгән…

Бөтен өмет стаканда кебек,
Матур итеп ясап – бәйрәмнәр.
Бөтенесе олы бер түгәрәк,
Бәйрәм, алдауларга әйләнгән.

Яңа канун кеше үзләштерә,
Алдамаган кеше надан кебек.
Стаканы – кеше сынау өчен,
Сыйламаган кеше саран кебек.

Түбәтәйләр кия башласакте,
Түребездә тора… стакан өйдә.
Без яшибез шундый гәҗәп илдә
Исемнәре әллә Стаканида…

# Яңадан

Яңадан мин туган кебек булам,
Дөньялар көндә яңа кебек…
Элек күзгә чалынмаганны,
Яңалыклар кебек итеп күреп…

Кире баштан, тәүге тапкыр,
Кичерешләр килә өр яңа
Гомер учаклары дөрли әле…
Мәңге сүнмәс кебек, гел яна.

Онытканнар кире искә төшә,
Ялгышлары борчый күңелне.
Барысыда бергә кушылалар,
Яңа тормыш итеп бүгенне.

Хисләр яңа, элек булмагандай,
Онытыла кайчак чынбарлык.
Күңел халәтедә кайвакытта,
Онытылып, җырлар җырларлык.

Чынлыкта, дөнья ул төрлечә,
Ничек күңел кабул итә ала…
Күрмәгәннәр ерак… читтә кала,
Күргәннәре сиңа була ала…

# Печән чапкан вакыт

Печән чапкан вакыт, җәй көннәре,
Тигез хәтфә кебек болыннар.
Атлар өчендә бит печән өсте,
Йөгерешеп уйный колыннар.

Балачаклары бит аларныңда…
Тәүге тапкыр алар болында.
Безнеңдә, шундый чак бар иде,
Гомерләрнең озын юлында…

Бөтенесе гел беренче тапкыр,
Барысыда булган яңалык.
Кайда алар ничек сакланадыр…
Вакыт вакыт ала яңарып…

Хәтер китаплары исән әле.
Бик күпләре язып куелган.
Юллар булып, алар өстәләләр,
Укыр өчен алып куеннан.

Печән өсте… аннан көзләр килә,
Уңышлары булып, җыйганның,
Хәләлләре күбрәк булса иде,
Файдалары булмас, тыйганның…

# Гомер җиле

Гомер җиле кебек тормышларда,
Аллаһының безгә биргәне.
Аның булган барлык сынаулары,
Һәм күрсәткән безгә ярдәме.

Уңай җилләр, юлны җиңеләйтә,
Каршы иссә… кеше чыныга.
Җилгә оча, я саклана ала,
Хыялларда… булган чыныда…

Абындыра җилләр, ашыктыра,
Хыялларны кайчак үзгәртә.
Ул җилләр бит, адаштыра ала,
Кыйбланны хәттә үзгәртә.

Югалуы түгел… таба алмау,
Җилләр кинәт тынып калсада.
Барган юлың аңлый алынмыйча,
Билгесезлек булып барсада…

Вакыт җитә, җилләр исми кебек,
Кеше бетә әллә күнегеп…
Ул җилләрне әллә сизмәс була,
Дөнья эшләренә күмелеп.

Гомер җиле исә икән әле…
Ул исмәсә, без бит булмыйбыз.
Чынбарлыктан әллә качмак булып,
Җилдәгедәй гамәл кылмыйбыз…

# Җәйнең киче

Җәйнең киче көтеп алынгандай,
Эссе көннәр һаман булганга.
Тынычырак булып кала кебек,
Караңгылык белән тулганда.

Акырын гыны киче якынлаша,
Көн кызуы шактый басылган.
Көтүләрдә инде урап кайтты,
Бушап калган урам башыннан.

Кояш баеый, сүнгән учак кебек,
Җылыларын җирдә калдырып.
Караңгылык үзе салкын кебек,
Утырасың утлар яндырып…

Син аңлыйсын төннәр бик тиз үтә,
Йоклап кына бары китәрлек…
Шунысыда ямьле җәйләр өчен,
Яллар өчен була җитәрлек.

Әтәч тавышлары… көтү чыга,
Караңгылык таңда тарала…
Җәйләр генә, шул кичләре белән,
Хәтерләрдә… истә кала ала…

# Күңелгә мунча

Тукай безгә күптән әйткән инде,
«Җанга мунча» дигән сүзләрне.
Бассейннар ясый башласакта,
Җанга караш бик аз үзгәрде.

Керләнгәндәй кием һәм тәннәр,
Күңелләрдә шактый керләнә.
Күңел мунчалары булса гына,
Пакьлана ала, кеше үзгәрә.

Ниләр соң ул күңел өчен мунча,
Күңел ниләр белән пычырый…
Юынмыйча …мин бик чистамын,
Диеп йөрүчеләр очырый…

Ихлас була алу, иң беренче…
Кешеләр һәм Аллаһ алдында.
Кылган гөнах – утын учакларга,
Керләр җанда, безнең янгында.

Тәүбәләр бар олы пычырактан…
Җомгалар бар атналар саен.
Гыйбәдәтләр Аллаһ карышында,
Вакытын тап син белеп җаен.

# Барабыз

Барабызда барабыз…
Үзгәрәме арабыз.
Барыр юллар булмагандай,
Яңа юллар салабыз.

Кая таба, кемнәр белә,
Кемнәр күрә юлларын.
Уйламыйча, аңламыйча,
Дөрес, ялгыш булганын.

Барабызмы, чабабызмы,
Аргамактай узышта…
Безнең артта беркемдә юк,
Китүче юк узыпта…

Кемнәргә иярәбездә…
Юлдашларыбыз кемнәр…
Бер файдасыз булмаслармы,
Юлда үтелгән көннәр.

Барабыз әле барабыз,
Якынаймый арабыз…
Кушылмаган җирдә йөреп,
Аймыл булып калабыз…

# Җыр көндәлдә

Күңел никтер җырга тартыла,
Ул чишмәдән… сусау басыла.
Моңлы җырга кереп китә кеше,
Кайгы төшкән чакта башына…

Берәү җырлый, берәү тыңлый ала,
Кемгә ничек сәләт бирелгән.
Сагынуларга җавап, җырын суза,
Ерак чакта туган җиреннән.

Күңел дулкыннары очрышып,
Йөрәк тибешенә кушылыр.
Хисләр җебе белән тоташтыру,
Җыр булуга сәбәп шушыдыр.

Үзе көе, үзе дулкынында…
Һәркемнеңдә якын җырлары.
Кәеф ачкычыдай булып кала,
Кеше күңелендә җыр бары…

Кабатлана алар эчтәлектә…
Ләкин төрле – төрле моңнары.
Ишетелә алмый һәркемнеңдә,
Күңелендә туган җырлары…

Бер күңелдә, җырлап, тыңланып,
Бер күңелдә генә моңланып.
Җырлангандай гомер җыры кебек,
Ишетелә ала соңланып…


Йорт

Дүрт стена гына түгел йортлар,
Идән белән түшәм куелган...
Сатып алып яки үзең төзеп,
Яшәр өчен кеше җыелган.

Савыт түгел мебель тезәр өчен,
Тәрәзәгә элеп челтәрләр...
Тузан җыеп ятса тырышканың...
Кемнәр килеп аны сөртәрләр.

Ул тулмаса, әгәр җылы белән,
Куыш булып җилдә, яңгырда.
Ышанычлы тыныч урын булып,
Кайткан чакта синең алдыңда.

Ишетсәләр сине...син ишетсәң,
Ул йортларда булып... үз ара.
Җылы өләшүче тормышларда,
Гаилә учагыда була ала...

Хөкүм сөрсә анда тыныч халәт,
Булса анда җылы карашлар.
Шундый йорты әгәр булмый икән,
Җирдә кеше була адашкан...

Йортың белән, калсын балаларың,
Утырталган, үскән агачын...
Белә алып нинди гамәлләрең,
Үзеңнән соң җирдә каласын.

Рузил Фазлыев
25.07.2021

# Тибә йөрәк

Тибә йөрәк, әле туктамыйча,
Эшләр эшем әле, димәк бар.
Кемдер өчен, бәлки үзем өчен,
Бу дөньяда әле кирәк бар…

Тибә йөрәк, арымаган кебек,
Көнен, төнен туктый алмый ул.
Аның тибүенә гомер бәйле,
Шулай икәнлеген аңлый ул.

Тибә йөрәк, тавыш бирми генә,
Нинди хәлдә, аны кем белә…
Ул тибүдән аны «коткара ала»,
Бары туктап калган көн генә.

Тибә йөрәк, туктамастай кебек,
Туктауларын теләү бик сирәк.,.
Ниләр генә җирдә кылсакта без,
Йөрәк тибүләре бит кирәк.

Тибә йөрәк, ә без онытабыз,
Кайвакытта аның типкәнен.
Аның тибүләре аркасында,
Гомерләрнең дәвам иткәнен…

# Бөдрә таллар

Еракларда калган, әй еракта…
Балачагым булып бөдрә таллар.
Истәлеге, кебек яшьлегемнең,
Ә талларым, шунда көтеп калган.

Таллар нигә шулай истә кала,
Су буйлары… моңсу булганга…
Үткән вакыт бөдрә таллар кебек,
Күз алдына килеп торганга…

Хәтер яңаруы… башка җирдә,
Шундый таллар үсә алганга.
Ошаганнар алар, ошаганнар,
Сөн буенда үскән талларга.

Җәйләр җитә, таллар бөдрәләнә,
Балачактан сәләм биргәндәй.
Бөдрә таллар- балачаклар булып,
Кунак булып җәен килгәндәй.

Бөдрә таллар тагын матурлана,
Сайрар өчен кошлар кунганда.
Балачагым якын кебек әле,
Бөдрә таллар җирдә булганда.

# Тамырлар

Тамырлары була һәр әйбернең,
Агачларның, хәттә гөлләрнең.
Күл буенда үскән тонбыекта,
Тамыр җәя суда… күлләрнең.

Җан иясе, нәселендә таба,
Тамырларын, нәсел җебендә,
Тамырлары аны саклап килә,
Яшәгәндә җирнең йөзендә.

Тамырлары була гамәлеңнең,
Кыла алган бөтен эшеңнең.
Дәвам итә, исән – иминлектә,
Тамырлары, камил кешенең.

Тамыр бит ул бик тирәнгә китә,
Мең яшәрлек агач – имәннең.
Тамырлары саклый ала бары,
Яшәргә дип җиргә килгәннең.

Сиңа кадәр булганнарны сакла,
Синнән соңда калсын тамырлар.
Әдәп саклап әгәр яши алсак,
Тамырларда таза калырлар…

# Кимчелек

Камиллекнең чиге булмагандай,
Кимчелекләр, бик аз түгелдер…
Язмышларга тәэсир итүче,
Кимчелекле урын – күңелдер.

Синдә дә бар инде кимчелекләр,
Миндә дә бар, алар житәрлек.
Алар сиңа мәңге ияргәндәй,
Көч табыла алмый бизәрлек.

Кимчелекләр була тумыштанда,
Язмышлардан шулай язылып.
Сорап алганнарга охшаганы…
Үз теләгең белән… ялынып.

Кимчелекләр күзне ача кебек,
Төзәтергә теләк туганда.
Кабатлыйсы килми кайберләрен,
Күңел түрләреннән куганда.

Буйсынмаган кебек кайвакытта,
Бар акылга, безнең теләккә.
Кабатлана алар еллар буе…
Авыр эзләр салып йөрәккә.

Кеше өчен артык әйбер булмый,
Анысыда бәлки кирәктер.
Йомшак урын була һәркемнеңдә,
Кимчелексез кеше сирәктер.

# Кояш баеп килә…

Кыен була тормыш, бу дөньяда,
Дога сүзен читкә этәрсәк.
Ялагайлык дуслык кебек диеп,
Ике флаг бергә күтәрсәк.

Түрә булса, аны хуҗа диеп,
Тормышларны аңа тапшырып.
Басу корып, иген үсмәс булса,
«Яңгыры юк» диеп гәп корып.

Күп сыналды халык мохтаҗлыкта,
Бирелмәде, өмет көч бирде,
Байлык сыналуы авыр икән…
Нәфесләргә шактый көч килде.

Юк вакытта, кеше юмартырак,
Булмаганны юк бит бирәсе.
Бар өстенә, кат кат өелгәндә,
Юмартлыкны килми күрәсе.

Тую сүзе шактый шартлы икән,
Чамаларын авыр табуы…
Байлык бит ул бүген булганнары,
Башка килми… барысы калуы.

Калу гына түгел, әле исраф булып,
Кирәксезгә түккән көч булып.
Көндезләре үтеп, китеп бара,
Кояш баеп килә, кич булып.

# Вакыт бар ул

Вакыт бар ул, нишләп булмасын,
Гомер әллә вакыт түгелме.
Тәүлек сиңа бүләк ителә бит,
Таңнар ату белән бүгенге.

Вакыт бар ул язмыш дәвам итсә,
Әрәм генә булып бетмәсә.
Чишмә суы тәмен кемнәр белә,
Учына алып суын эчмәсә…

Вакыт бар ул теләкләрең булса,
Тирә якка карап алырга.
Урманнарда сукмак эзләмичә,
Киң юллардан барып калырга.

Вакыт бар ул, ләкин үтә тора,
Һәр көннәре, һәрбер сәгате.
Кеше күңеленә салынган бит,
Кадерлене саклау гадәте.

Вакыт бар ул, әгәр уйлана алсак…
Ул вакытның каян килгәнен.
Гомер озынлыгы итеп безгә,
Кемнең кешеләргә биргәнен.

# Сөенү

Күмелә ул шатлыкларга,
Шуны тоеп сөенә.
Эшкә чыгып киткәндә дә,
Кайтканда да өенә…

Өмет булган, хыялпары,
Барлыгына сөенә…
Үзе юлларыннан бара,
Йөрми кеше көенә.

Сөенерлек була икән,
Язмышының бүгене.
Шундый халәттә буладыр,
Сөенерлек күңеле.

Сөенә күңел, сөенә,
Сөенә белгәненә.
Юлларында сөенерлек,
Сәбәпләр күргәненә.

Таңнар атуга сөенә,
Яңгырлар яуганына.
Сөенечләргә уралып,
Тормышлар барганына.

# Хыял аты…

Кичә генә кебек ул вакытлар,
Басу юлы, аның тузаны…
Шул буладыр, кинәт аңлый алу,
Бик тиз кебек, гомер узганын.

Әллә ниләр эшләр кебек идем,
Әллә ниләр кала эшләнми.
Хыял аты һаман жигүледә…
Алга ашкынып, инде кешнәми.

Күпме калды, матур теләк булып,
Хыялларга тирән күмелеп.
Агач булып алар үсмәгәннәр,
Тормыйлар шул хәзер күренеп.

Йөрәк яшь дип кемдер хыяллана,
Карт акылга, нигә яшь йөрәк.
Бала акылы кайту кебек бит ул,
Бәйрәмнәрдә йөзәр яшь теләп.

Яшьлек чакка, дөрес сылтап була,
Картаюны таный алмыйча…
Үткән гомереңне вакыт вакыт,
Дөрес итеп саный алмыйча.

# Тәүбә кая…

Изге айлар тагы үтеп китте,
Килә алмыйча һаман иманга.
Исраф булган кебек алтын вакыт,
Тәүбә сүзен ныклап уйларга.

Богауланган айда бөтен шайтан,
Вәсвәсәләр бетеп торганда.
Тәкбирләре, гает азаннары,
Манарадан чакырып торганда,

Мөмкинлекнең бәлки соңгылары,
Сизелмичә генә югалды…
Өметләрме барыбер кабынмыйча,
Офык артларына юл алды…

Татып карамыйча аңлау авыр,
Иманныңда нинди булуын.
Тәүбә итү, күңелләргә бирә,
Иман нуры белән тулуын…

Бик аяныч әгәр ишетмәсәк,
Раббыбызның әйткән сүзләрен.
Нигъмәтләрен кире каккан кебек,
Гомер диеп дөнья гизгәнең…

Тәүбә бит ул бары аңлый алу,
Ялгышларың чиксез булганын.
Төзәтергә теләп син шуларны,
Таба алганың дөрес юлларын.

# Кая була вакыт

Кая була вакыт, кая китә,
Агамы ул, әллә бетәме.
Гомер буе безнең белән булып,
Көтмәгәндә ташлап китәме.

Кая була… сәгатьтә ком кебек,
Бер мизгельгә генә җитәме.
Ашыктырып, тирән уйландырып,
Ул үзенең колы итәме.

Күрмәгәнне аңлау авырырак,
Сизү өчен кирәк, фикерләү…
Вакыт белән ипле булу кирәк,
Аны узып «лутчы» сикермәү.

Вакыт юлдаш, чордаш, уйдаш,
Сорауларга җавап биручe.
Онытылган диеп уйлаганны,
Үткәннәрдән апып килүче…

Аллаһының бер нигъмәте генә,
Кая китә… белә алмабыз…
Ул вакытның кадерләрен белсәк,
Авыр хәлләрдә без калмабыз.

Кая була вакыт… уйлап кара…
Сиңа бирелгәнен булсада…
Вакыт юк дип әйтү гөнаһ булыр,
Дөнья эше өелеп торсада…

# Утырасы иде

Әйтәселәр байтак җыелганга…
Бер утырасы иде сөйләшеп.
Кайвакытта җиңелермен кебек,
Авыр уйлар белән көрәшеп.

Үкенгәннәр, әллә үтелгәннәр,
Кабат – кабат килә уйларга.
Шикле хисләр кинәт усалланып,
Теләгәндәй тотып кыйнарга.

Кереп оялаган йөрәгемә,
Гомер чыга алмаслыклары.
Юллар көтә кебек никтер алда,
Үзең теләп бармаслыклары.

Утырасы иде бер сөйләшеп,
Фикер киңәш белән, кичләрен.
Таралырлар иде шул вакытта,
Авыр болыт кебек хисләрем…

Сынаулары булсын – барысыда,
Шулай итеп, кабул итәек…
Барысыда үтә бу тормышта,
Бу халәттә… сабыр итәек…

Утырасы иде бер сөйләшеп,
Уйлар хисләр белән бүлешеп.
Иң кыйммәте шундый кеше булу,
Сөйләшерлек, шулай күрешеп…

# Күңел нинди

Аллаһ сүзен, сүздә кушып кушып,
Гыйбәдәттә әгәр булмасак,
Кушканнарын аның үтәмәсәк,
Гамәлләрен белеп кылмасак…

Купшы кием, купшы сүзләр алар,
Тамашалар өчен бик кирәк.
Күз буяуга барысы ошап кала,
Шөкер сүзең булса бик сирәк.

Күңеленә һәркем үзе хуҗа…
Нindиләрдән генә булсада.
Азлап азлап ул күренеп ала,
Нинди генә гамәл кылсада.

Бер карашы, бер җөмләсе житә,
Кешеләрне кайчак аңларга.
Кеше гомередә бит аз була,
Кайбер күңелләрне аңларга.

Серле дөнья кебек ул күңелләр,
Белеп бетерү мөмкин түгелдер.
Безне җиһан белән бәйләүчедә,
Кешеләрдә, шул ук күңелдер.

# Авыл бетми

Авыл бетә диеп чаң сугалар,
«Бетүләргә» юллар салганнар…
Зарланырга өйрәнмәгәннәр бит,
Авылында яшәп калганнар.

Бер яктан ул туган җирләр булса,
Икенчедән яшәү халәте.
Барысында халәл хезмәт белән,
Таба ала белү гадәте…

Авыл бетми, авыл бетә алмый,
Исемнәре бәлки үзгәрер.
Бутап булмый гадел караганда,
Авыл кешесенең йөзләрен.

Шәһәрләрдә җиңел тормыш эзләү,
Тәккәберлек бераз катыш ул.
Читтән күзәт; авыл малаеның,
Шәһәреннән кайчак кайтышын…

Рәхәт тормыш шулай төзеләме,
Әллә шулай качып китүме…
Олы көтүләргә кушыла алып,
Тормышларны җиңеләйтүме.

Шелтә була алмый берәүгәдә,
Кешеләрнең язмыш юллары.
Ихласырак, гаделерәк кебек,
Авыл кызы, авыл уллары…

# Соңгы өмет

Соңгы өмет кебек яңгырыйдыр,
Иң кирәген әйтеп калулар.
Сәнәк белән суга язу кебек…
Кыек мыек, сыза алулар…

Аерылышуны көтү кирәк түгел,
Булмый калмас, алар булырлар…
Өметсезлек кебек тоелсада,
Олы өмет белән тулырлар…

Очрашулар кайчак кирәк булмый,
Әйтәселәр инде әйтелгән.
Башка юллар инде алда көтми,
Кирәк җиргә барып җителгән,

Җирдә тормыш эшкә йөргән кебек,
Һәр кешенең үзе һөнәре…
Эшкә бару, эштән кайту белән,
Үтеп китеп бара көннәре.

Эш белән бит барысы бетми әле,
Башка гамәлләре җитәрлек…
Тамак туйдырулар белән бергә,
Кешеләрне, кеше итәрлек.

Барысыда кала, юкка чыга…
Байлыкларың, кылган эшләрең.
Бәлки саклап булыр булган хиснең,
Шигырь юлларына күчкәнен…

Бетмәс юлда кебек гомер вакыт,
Еракларга кеше ашкына…
Билге булып, кала җир өстендә,
Соңгы тапкыр куйган таш кына…

# Биектә

Биеклекне кеше бик ярата,
Бәләкәйдән биек хыяллар…
Ул гомердә, күпме җыелада…
Бер күңелгә ничек сыя алган.

Биектәрәк булу кулаеырак,
Бер баскычка гына булсада.
Сәхнәләрдә биегерәк була,
Халык белән клуб тулсада.

Каланчалар булган, манаралар,
Ераклардан алар күренгән.
Биектәрәк кебек хисләреңдә,
Чыккан чакта йөрәк түреннән.

Кошларда бит биекләрдән оча,
Күрер өчен барыр юлларын.
Догаларын кыла кешеләрдә,
Биекләргә сузып кулларын.

Яктылыкта биекләрдә кебек,
Караңгылык, аста түбәндә.
Таңнар атмас кебек кайвакытта,
Чарасыздан башны игәндә.

# Бер сандыкта

Күңел әллә үзе мине тыңлый,
Мин тиешме аны аңларга…
Кабатланып диңгез дулкыныдай,
Ташланганда хисләр ярларга.

Ул ашкына, хәттә белеп булмый,
Ниләр теләп, ниләр сизенеп.
Вакыт- вакыт күңел теләгәннәр,
Юкка чыга… очып, сибелеп.

Күңел миндә, әллә мин күңелдә,
Кемдә теләк, кемдә ышану…
Икеләнү килеп туган чакта,
Шикләнүдән ансат бушану.

Барысыда бергә җыелганда,
Күңел, уең, бергә хыялларың…
Сакларгамы аны, сайларгамы,
Бер сандыкта булса җыя алганың?

Маҗаралар кайчак эзләгәндәй,
Чакыра ул әллә кайларга…
Барысына барыбер җитешмисең,
Ялгышмыйча кайсын сайларга.

Бар ышаныч кала, бер акылда,
Тыңлый алсак, бары ул гына.
Җиңелерәк үтелерләр кебек,
Акыл белән үткән юл гына…

# Гаделлек

Гаделлек сорыйбыз, эзлибез,
Кайвакыт, таләпләр итәбез.
Без аны яшәүдә, тормышта,
Күпвакыт беряклы итәбез.

Әйбернең хакы бар, чамасы,
Изгелек сорыйдыр җавабын.
Сораулар дөресме үзеңә,
Эшеңдә күрмәсәң савабын.

Гаделлек туганча, дусларча,
Тик сорау шикелле булмасын.
Гаделлек күңелдә булганда,
Беркайчан буш гамәл булмас ул.

Язмышка буйсыну гаделлек,
Ул синең тормышта өлешең.
Кадерен белә алып, алдамый,
Алданмый яшәвең… йөрешең.

Гаделлек яхшыга омтылу,
Холыкка әйләнеп күңелдә.
Кылынган саваплы гамәлдәй
Таяныч, ышаныч бүгенгә.

# Туган нигез

Кайвакытта туган нигез диеп,
Матур матур сүзләр сөйлибез.
Сагынгандай булып, уйга батып,
Моңлы моңлы көйләр көйлибез.

Үткән вакыт инде барысыда,
Хисләр генә бераз яңара…
Ни булсада, ул буш калган хәзер,
Ул хужасыз булып санала.

Вакытында җылы түбә булган,
Давамнары нәсел җепләре…
Хуҗасызлык картайтада кебек,
Кире кайтмагачтан… көткәне.

Хисләр генә бераз җанланалар,
Күргәннәрдән, искә алганнан.
Язмышларда кайчак шулай була,
Онытылганнар, ялгыз калганнар.

Туган нигез, вакыт галәмәте,
Үсеп житеп… юллар салганда.
Барыбердә гадел кебек тугел,
Туган нигез ялгыз калганда…

# Җәй рәхәте

Җәй рәхәте әнә тирә якта,
Яңгырларсыз эссе көннәре.
Җиләс су буйлары яшеллектә,
Елгалары белән күлләре,

Җәй асылы ул бит җылылыкта,
Эсселеккә бераз авышып.
Үзгәртәлмәс кебек бу тынлыкны,
Коеп яуган яңгыр тавышы…

Бөтен җиһан чәчәк ата кебек,
Булсаларда сусау дымнарга.
Нидә булса җитми кебек инде…
Шөкер әйтеп калыйк булганга.

Бүгенгеләр өчен, үткән өчен,
Бу җәйләрне күрә алганга.
Гомер юлы сәяхәтләрендә,
Булганнарны күреп калганга.

Аңлар өчен эссе, сусауларны,
Җир йөзендә булып торганын.
Сакланырлык күләгәләр булыр,
Догаларың булса… кылганың…

# Таңнары, чишмәләре

Торамы соң бездән таңнар ату,
Ничә тапкыр алар атсада.
Артык мөһим микән кеше өчен,
Бәхетләрен кайда тапсада.

Без саныйбыз анын атканнарын,
Һәркемнеңдә үзе таңнары.
Яңа көннәр туып… гомерләрнең,
Була инде үтеп барганы…

Гомер сәгатләре кебек таңнар көннәр,
Берсе артыннан, берсе ашыга.
Ә елгасы ага, ага шулай,
Кайта алмый чишмә башына.

Челтрәп аккан чишмә тавышыдай,
Еракларда кала балачак…
Сусаганда… сусамаганда да,
Чишмә суы татлы булачак.

Әй чишмәләр, кайда калдылар соң,
Агымнарын саклый аламы…
Элеккечә кебек булмаса,
Чиста сулар челтерәп агамы.

# Ялгыш «тумыш»

Уңы сулы була, парлы булса,
Ике сыңар, парлы булалмый,
Ике ир ат, яки хатын кыз,
Берничектә тормыш кора алмый.

Йомшаклыкта көче хатын кызның,
Нәфислеге – аның билгесе.
Шуны аңлап яши акыллысы,
Ир булырга тели тилесе.

Хатын-кыздай булмый ир атларда,
Ир исемен, итеп мәсхәрә.
Җимеш итеп карап яшәсәдә,
«Җимешем» дип аңа дәшсәдә.

Хатын кызмы, әллә ир атмы ул,
Кием генә әллә аера…
Үз асылы әллә онытыла,
Каршы якка күңеле каера…

# Чынбарлык

Кеше белә микән һәрвакытта,
Күңелләре нидән үрелгән.
Хәтерләрдә ниләр саклана икән,
Уйланулар… Әллә күрелгән…

Хыялларың бәлки истә калыр,
Чынбарлыкта булган шикелле.
Шул уйларны искә ала – ала,
Әрәм итеп озын кичеңне.

Уйларда бит… кала тирән булып,
Язмышларны кинәт үзгәртеп.
Аларда бит безнең белән бара,
Артык борчымыйча, күзәтеп.

Буталада кебек уйлар, хисләр,
Дәфтәр битләрендә, үткәннәр.
Булганнары, була язганнары,
Хәтерләргә күчеп беткәннәр.

Күңелеңдә булган, үзең белән,
Байлыгыңда – синең күрәсең…
Мөмкин түгел барсын укып чыгу,
Бик килсәдә аны беләсең…

# Юлда барасы

Барсы алда, барлык күрәселәр,
Шатлыклары белән сынаулар.
Яктылыгы алда, өмет шунда,
Күзләредә, шунда кыраулар…

Офыклардан нидер килер кебек,
Алда тора бары офыклар…
Давыллардан, булган эсселәрдән,
Безгә анда нинди ышык бар…

Финишлары белән юл башлары,
Ишетсәктә, берәү күрмәгән.
Ә күргәннәр… шулай тиеш диеп,
Мәңгелектән хәбәр бирмәгән.

Бер төш кебек булыр җирдәгеләр,
Үтеп кителердә, онытылыр.
Бөтен халык үтәр өчен булган,
Безне көтеп, олы юлы торыр.

Кеше җаны мәңге булыр дигән,
Ышанмаска аңа ярамый…
Ышанмасаң, сиңа ышанмаслар,
Ышанмыйча яшәү ярамый.

Безнең күнел һәрчак мохтаҗ була,
Җылы сүзләр, туры юлларга.
Вакыт җитми кала фикерләргә,
Һәр вакытта юлда булганга…

# Гомер юлым

Барам әле тапкан юлларымнан,
Карый – карый тирә ягыма,
Карап торам елга ташуларын,
Менеп басып биек ярына.

Атлаганда, вакытыда үтә,
Барыр юлларыңда кыскара.
Адым үлчи гомер озынлыгын,
Күпмеләре… үтә бушкада…

Мосафиры булып гомереңнең,
Тормыш үтә, булып сәфәрдә.
Яратылган әдәм балалары,
Юлчы булып жирдә яшәргә.

Кайвакытта… олы агайларда,
Комда уйнаган нәни баладай.
Кояш чыгып, кояш батып килә…
Кайтуында уйлап карамай…

Юллар шуңа төрле, төрле була,
Шунадырда алар бормалы.
Барам әле үзе юлым белән,
Кулай булыр, миңа булганы.

Үтәм әле алда булганнарын,
Кайда булсаларда уйларым.
Язганнарын миңа үтәсе бит,
Алар минем гомер юлларым…

# Челләсе

Челлә – җәйнең эссе вакытлары,

# Конец ознакомительного фрагмента.

Текст предоставлен ООО «ЛитРес».

Прочитайте эту книгу целиком, купив полную легальную версию на ЛитРес.

Безопасно оплатить книгу можно банковской картой Visa, MasterCard, Maestro, со счета мобильного телефона, с платежного терминала, в салоне МТС или Связной, через PayPal, WebMoney, Яндекс.Деньги, QIWI Кошелек, бонусными картами или другим удобным Вам способом.